МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2022 Казан ш. № 18-77

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 18.10.2010 ел, № 18-90 боерыгы белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең муниципаль бурыч кенәгәләрендә чагылдырылган бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 18.10.2010 ел, № 18-90 боерыгы белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең муниципаль бурыч кенәгәләрендә чагылдырылган бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу боерыкның рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керүен билгеләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы-
ның
___2022 ел, ___№
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 18.10.2010 ел, № 18-90 боерыгы белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең муниципаль бурыч кенәгәләрендә чагылдырылган бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

1. 1 пунктта:

өченче абзацта “алынган” дигән сүзне “җәлеп ителгән” дигән сүзләргә алыштырырга;

бишенче абзацта “башкалар” дигән сүзне “башкалардан” дигән сүзгә алыштырырга:

2. Әлеге Тәртипкә № 2 кушымтада:

атамасында “алынган” дигән сүзне “җәлеп ителгән” дигән сүзләргә алыштырырга;

таблицаның 10 графасы атамасында “алу” дигән сүзне “җәлеп итү” дигән сүзләргә алыштырырга;

3. Әлеге Тәртипкә № 3 кушымтадагы таблицада:

8 графадан соң «Муниципаль гарантиянең чик суммасы” 8.1 графасын өстәргә;

16 графа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү срогы гарантка билгеләнгән тәртиптә таләпләр куелганнан соң (дд.мм.гг.)»;

16 графадан соң «Гарантның гарантия буенча йөкләмәләрен фактта үтәү датасы» (дд.мм.гг.)» 16.1 графасы һәм «Гарантның муниципаль гарантиядән килеп чыгучы йөкләмәләрне фактта үтәү күләме (сумнарда)” 16.2 графасын өстәргә;

17 графаның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гарантның гарантияне үтәү буенча бурычы (сумнарда) »;

17 графадан соң «Принципалның муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең йөкләмә валютасында факттагы күләме» 17.1 графасын өстәргә;

18 графа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль гарантиядән килеп чыгучы йөкләмәләр күләме (сумнарда)».

4. Әлеге Тәртипкә № 4 кушымтада:

атамасында «башкалар» дигән сүзләрне «башкалардан» дигән сүзгә алыштырырга;

таблицада 11 графа атамасында “алынган” дигән сүзне “җәлеп ителгән” дигән сүзләргә алыштырырга;